**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5819**
**03.09.2021**

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль белем бирү оешмаларын үстерү буенча проектлар конкурсы турында

Белем бирүнең сыйфатын күтәрүне стимуллаштыру һәм белем бирү эшчәнлегендә югары нәтиҗәләргә ирешүне тотрыклы тәэмин итүче муниципаль белем бирү оешмаларына ярдәм итү, оешмаларның педагогик коллективын профессиональ үстерү максатларында, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәгариф идарәсенә Яр Чаллы шәһәренең муниципаль белем бирү оешмаларын үстерү буенча проектлар конкурсын (алга таба – конкурс) 2021 елның сентябрендә үткәрергә.

2. Расларга:

1) конкурс турында нигезләмәне 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурс комиссиясе составын 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурс нәтиҗәләре буенча чыгымнарны финанслауны 2021 елга шәһәр бюджетының «Мәгариф» тармагында башка мәсьәләләр» 07.09 бүлеге/бүлекчәсе буенча каралган акчалар хисабына 3000 000 (өч миллион сум) сум күләмендә тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 3 сентябрендәге
5819 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль белем бирү оешмаларын
үстерү буенча проектлар конкурсы турында
нигезләмә

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә Яр Чаллы шәһәренең муниципаль белем бирү оешмаларын үстерү буенча проектлар конкурсын (алга таба – конкурс) оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

2. Конкурсны оештыручы булып Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының мәгариф идарәсе тора.

## 2 бүлек. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

3. Конкурс Яр Чаллы шәһәренең муниципаль белем бирү оешмаларын үстерү, муниципаль белем бирү оешмаларының уңай эш тәҗрибәсен тарату, шулай ук мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, гомуми белем бирү учреждениеләре, өстәмә белем бирү учреждениеләре педагогик коллективларының иҗади эшчәнлеген активлаштыру, педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгын үстерү, инновацион эшләнмәләр һәм технологияләргә ярдәм итү, педагогик коллективларны һөнәри үстерү максатларында үткәрелә.

4. Конкурсның бурычлары:

1) белем бирү оешмаларының алдынгы эш тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм пропагандалау;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль белем бирү оешмалары педагогик коллективларының иҗади, сыйфатлы, инновацион эшләвен, аларның һөнәри үсешен стимуллаштыру;

3) Яр Чаллы шәһәре халкы өчен конкурентлыкка сәләтле белем бирү хезмәтләрен үстерүгә ярдәм итү;

4) киң җәмәгатьчелек катламнары, җирле үзидарә органнарының игътибарын шәһәр мәгариф системасын үстерү проблемаларына җәлеп итү;

5) грант алуга ачык конкурста катнашу өчен тигез мөмкинлекләр юлы белән муниципаль белем бирү оешмаларының инициативаларын тормышка ашыру өчен шартлар тудыру.

## 3 бүлек. Конкурста катнашу критерийлары

5. Конкурс Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан, түбәндәге таләпләргә җавап бирә торган муниципаль белем бирү оешмалары арасында үткәрелә:

1) эшчәнлекләрендә Россия Федерациясенең мәгариф һәм хезмәт законнарын бозу ачыкланмаган оешмалар;

2) педагогик кадрлар белән тулысынча тәэмин ителгән оешмалар;

3) белем бирү сыйфаты буенча уңай динамикага һәм югары нәтиҗәләргә ия булган оешмалар.

6. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен составы Башкарма комитет карары белән раслана торган конкурс комиссиясе (алга таба - конкурс комиссиясе) төзелә.

7. Конкурста катнашучылар конкурс комиссиясе тарафыннан түбәндәге номинацияләр буенча бәяләнә:

1) гимназияләр, лицейлар, аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган мәктәпләр арасында иң яхшы белем бирү оешмасы.

Проектларның өстенлекле юнәлеше:

- «9, 11 нче чыгарылыш сыйныф укучыларын дәүләт йомгаклау аттестациясенә нәтиҗәле әзерләү»;

- «Бөтенроссия предмет олимпиадасына нәтиҗәле әзерлек»;

- «Муниципаль биремне нәтиҗәле үтәү»;

2) гомуми белем бирү мәктәпләре арасында иң яхшы белем бирү оешмасы.

Проектларның өстенлекле юнәлеше:

- «9, 11 нче чыгарылыш сыйныф укучыларын дәүләт йомгаклау аттестациясенә нәтиҗәле әзерләү»;

- «Бөтенроссия предмет олимпиадасына нәтиҗәле әзерлек»;

- «Муниципаль биремне нәтиҗәле үтәү»;

3) өстәмә белем бирү учреждениеләре арасында иң яхшы белем бирү оешмасы.

Проектларның өстенлекле юнәлеше:

- «Өстәмә белем бирү учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәле, мониторинг күрсәткечләре (критерийлары)»;

- «Муниципаль биремне нәтиҗәле үтәү»;

4) мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре арасында иң яхшы белем бирү оешмасы.

Проектларның өстенлекле юнәлеше:

- «Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәле, мониторинг күрсәткечләре (критерийлары)»;

- «Муниципаль биремне нәтиҗәле үтәү».

## 5 бүлек. Конкурсны үткәрү сроклары һәм тәртибе

8. Конкурста катнашу өчен заявка һәм муниципаль белем бирү оешмасын үстерү буенча проект тапшырырга кирәк. Заявкада белем бирү оешмасының исемен, конкурс номинациясен һәм проектның өстенлекле юнәлешләрен күрсәтергә кирәк. Проект үз эченә түбәндәгеләрне ала: проектның максатлары һәм бурычлары, проектның актуальлеген, кирәклеген һәм мөһимлеген тасвирлау, проектта катнашучылар, проектның тасвирламасы: куелган максатларга ирешү стратегиясе һәм механизмнары, проект чараларының тулы планы, проектны тормышка ашыруның кыска сроклы һәм озын сроклы нәтиҗәләре. Документлар мәгариф оешмасы җитәкчесе имзасы һәм мөһер белән раслана. Башлангыч сайлап алу нәтиҗәсендә проект критерийларына туры килми торган заявкалар төшереп калдырыла.

9. Конкурс 2021 елның сентябрендә өч этапта үткәрелә:

1 этап – 2021 елның 2 сентябреннән 7 сентябренә кадәр – конкурс материаллары Башкарма комитетның мәгариф идарәсенә тапшырыла, 324 кабинет, тел. 30-57-29;

2 этап – 2021 елның 8 сентябреннән 13 сентябренә кадәр –конкурс материалларына экспертиза. Бәяләү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе иң яхшы проектлар рейтингын төзи;

3 этап – 2021 елның 14 сентябреннән 17 сентябренә кадәр – конкурс комиссиясе беркетмәсе нигезендә конкурс нәтиҗәләрен игълан итү.

10. Конкурс комиссиясе конкурсны үткәрү вакытларын билгели, тәкъдим ителгән заявкаларны, проектларны карап тикшерә, иң яхшы проектларны билгеләү өчен тәкъдим ителгән проектларга түбәндәге критерийлар буенча бәя бирә:

1) проект хәл итәргә тиешле проблеманың актуальлеге һәм мөһимлеге;
2) нәтиҗәлелек;
3) чаралар планын тиешенчә эшләү;
4) тәкъдим ителгән проектларның эстетик бизәлеше.

11. Һәр критерий максималь 5 балл белән бәяләнә. Мәктәп конкурс комиссиясенең бер әгъзасыннан максималь 20 балл алырга мөмкин. Суммар максималь балл-180 балл.

12. Конкурс комиссиясенең барлык әгъзалары тарафыннан барлык критерийлар буенча куелган баллар суммасы проектның йомгаклау бәясен тәшкил итә. Бәяләү нәтиҗәләре буенча баллар җыю тәртибендә иң яхшы проектлар рейтингы төзелә һәм һәр номинациядә җиңүче һәм лауреатлар билгеләнә.

13. Конкурс комиссиясе карары буенча проектларны бәяләү өчен махсус белеме һәм квалификациясе булган экспертлар җәлеп ителә ала.

14. Конкурста катнашу өчен бирелгән документлар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

15. Конкурс җиңүчеләренә – җитәкчеләргә, педагогик хезмәткәрләргә, укыту-ярдәмче персоналга белем бирүнең сыйфатын арттыруны стимуллаштыру максатында акчалата бүләк бирелә:

- гимназияләр, лицейлар, аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган мәктәпләр арасында иң яхшы белем бирү оешмасы – 1 000 000 сумлык грант;

- гомуми белем бирү мәктәпләре арасында иң яхшы белем бирү оешмасы – 1 000 000 сумлык грант;

- өстәмә белем бирү учреждениеләре арасында иң яхшы белем бирү оешмасы– 500 000 сумлык грант;

- мәктәпкәчә белем бирү оешмалары арасында иң яхшы белем бирү оешмасы– 500 000 сумлык грант.

16. Җиңүче муниципаль белем бирү оешмасы Башкарма комитетның мәгариф идарәсенә агымдагы ел ахырына кадәр акчаларны файдалану турында финанс хисабы тапшыра.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2021 елның 3 сентябрендәге
5819 номерлы карарына
2 нче кушымта

Конкурс комиссиясе
составы

| № т/б | Ф.И.А.и. | Вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Хәлимов Р.М. | комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 2. | Хуҗин Р.Н. | комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе башлыгы |
| | | комиссия әгъзалары: |
| 3. | Бросалина Т.Г. | Башкарма комитет мәгариф идарәсенең балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү бүлекчәсе мөдире |
| 4. | Золотарева Л.В. | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе башлыгы урынбасары |
| 5. | Касыймова Р.Р. | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе башлыгы урынбасары |
| 6. | Кашапов Н.В. | Башкарма комитет мәгариф идарәсе башлыгының беренче урынбасары |
| 7. | Нестерова Н.А. | «Мәгълүмати-методик үзәк» МБУ директоры |
| 8. | Филатова С.В. | «Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләрен финанслау үзәге» МБУ директоры |
| 9. | Хәлиуллин Ф.А. | Яр Чаллы шәһәре мәгариф хезмәткәрләренең профсоюз оешмасы рәисе (килешү буенча) |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева